**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 5 июнь № 339

г. Казань

Татарстан Республикасының икътисадый зоналарында коммерциячел булмаган оешмаларның муниципальара ресурс үзәкләре эшләвенә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен һәм Татарстан Республикасы коммерциячел булмаган оешмаларының мәгълүмати порталын тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм күрсәтү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Татарстан Республикасының икътисадый зоналарында коммерциячел булмаган оешмаларның муниципальара ресурс үзәкләре эшләвенә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен;

Татарстан Республикасы коммерциячел булмаган оешмаларының мәгълүмати порталын тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен.

2. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына 30 көн эчендә субсидия бирүгә заявка, субсидия бирү турында карар, субсидия бирү турында килешү, субсидиядән файдалану турында хисап формаларын расларга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\339.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 5 июнь, 339 нчы
карары белән расланды

Татарстан Республикасының икътисадый зоналарында коммерциячел булмаган оешмаларның муниципальара ресурс үзәкләре эшләвенә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасының икътисадый зоналарында коммерциячел булмаган оешмаларның муниципальара ресурс үзәкләре эшләвенә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр (алга таба – субсидия) бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм күрсәтү» ярдәмче программасының Татарстан Республикасының икътисадый зоналарында коммерциячел булмаган оешмаларның муниципальара ресурс үзәкләре эшләве буенча чараны үтәүче коммерциячел булмаган оешмаларга (алга таба – коммерциячел булмаган оешма) тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына (алга таба – Акча белән баш эш итүче) расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

3. Субсидияләр субсидия бирү турында килешү төзергә планлаштырыла торган айга кадәр килгән айның бересенә түбәндәге таләпләргә туры килгән коммерциячел булмаган оешмаларга бирелә:

коммерциячел булмаган оешма Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән һәм үзенең эшчәнлеген гамәлгә ашыра;

коммерциячел булмаган оешманың Россия Федерациясе законнары нигезендә үтәү вакыты җиткән Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычы булмаска тиеш;

коммерциячел булмаган оешманың Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләре (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән) кайтару буенча вакыты чыккан бурычы һәм Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына башка вакыты чыккан бурычы булмаска тиеш;

коммерциячел булмаган оешма үзгәртеп оештыру, ябылу, банкротлык процессында тормаска тиеш һәм аның хуҗалык эшчәнлеген алып гамәлгә ашыруга чикләүләре булмаска тиеш;

коммерциячел булмаган оешма теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган салым салуның ташламалы салым режимы бирә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләре үткәргәндә мәгълүмат ачу һәм бирү күздә тотылмаган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналар) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган устав (җыелма) капиталларындагы чит ил юридик затлары катнашу өлеше барысы бергә 50 проценттан арткан чит ил юридик заты, шулай ук Россия юридик заты булмаска тиеш;

коммерциячел булмаган оешма башка норматив хокукый актлар, муниципаль хокукый актлар нигезендә әлеге Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатларга Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан акча алучы булмаска тиеш.

4. Субсидия аларны финанслар белән тәэмин итү чыганагы булган коммерциячел булмаган оешма чыгымнары юнәлешләре булып түбәндәгеләр тора:

хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру;

хезмәт өчен түләүгә исәпләнгән акча;

эш урыннарын җиһазлау өчен төп чараларны сатып алу;

чыгым материаллары алу;

чит оешмалар һәм физик затларның хезмәтләре өчен түләү;

мәгълүмати ярдәм күрсәтү;

белем бирү эшчәнлеге һәм семинарлар үткәрү;

төп эшчәнлекне гамәлгә ашыру буенча башка чыгымнар.

5. Субсидия алу өчен коммерциячел булмаган оешма Акча белән баш эш итүчегә түбәндәге документларны тапшыра:

Акча белән баш эш итүче раслаган форма буенча субсидия бирүгә заявка;

субсидия аларны финанслар белән тәэмин итү чыганагы булган чыгымнарның юнәлешен раслый торган документлар (финанс-икътисадый нигезләмә);

кредит оешмаларында ачылган хисап (агымдагы) счетлар турында салым органы биргән яки раслаган белешмә;

коммерциячел булмаган оешманың штат расписаниесе;

узган финанс елы өчен коммерциячел булмаган оешма Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлеген җайга сала торган федераль законнарның аерым нигезләмәләрен тормышка ашыру чаралары турында» 2006 ел, 15 апрель, 212 нче карары нигезендә Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә тапшырган хисаплылык күчермәсе;

коммерциячел булмаган оешманың әлеге Тәртипнең 3 нче пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында коммерциячел булмаган оешма җитәкчесе һәм баш бухгалтеры имзалаган белешмә;

Россия Федерациясе законнары нигезендә үтәү вакыты җиткән Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка

мәҗбүри түләүләр буенча бурычы булмавы, шулай ук Россия Федерациясе бюджет системасы тиешле бюджетына башка бурычлары булмавын раслый торган документ;

коммерциячел булмаган оешманың үзгәртеп оештыру, ябылу, банкротлык процессында тормавы һәм аның хуҗалык эшчәнлеген алып гамәлгә ашыруга чикләүләре булмавы турында коммерциячел булмаган оешма җитәкчесе имзалаган гарантия хаты.

Документлар коммерциячел булмаган оешма тарафыннан кәгазьдә һәм электрон мәгълүмат саклау җайланмасында тапшырыла.

Тапшырыла торган мәгълүматларның дөрес булмавы өчен коммерциячел булмаган оешмалар Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап тота.

6. Акча белән баш эш итүче гаризаны кертелгән көнендә терки һәм документлар тапшырылган көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә аларны карап тикшерә һәм субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту хакында карар кабул итә.

7. Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

а) әлеге Тәртипнең 5 нче пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

б) тапшырылган документларның, аларда булган мәгълүматларның әлеге Тәртиптә каралган таләпләргә һәм шартларга туры килмәве;

в) коммерциячел булмаган оешма биргән мәгълүматның дөрес булмавы.

Документлар әлеге Тәртипнең таләпләренә туры килмәгән очракта Акча белән баш эш итүче алар кертелгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган ике көн эчендә коммерциячел булмаган оешмага бу турыда хәбәрнамә җибәрә.

8. Субсидия бирү өчен нигез булып Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән бертип форма нигезендә Акча белән баш эш итүче һәм коммерциячел булмаган оешма арасында төзелә торган субсидия бирү турында килешү (алга таба – Килешү) тора.

9. Субсидия бирү турында карар кабул иткән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә Килешү проекты Акча белән баш эш итүче тарафыннан коммерциячел булмаган оешмага имзалау өчен җибәрелә.

10. Коммерциячел булмаган оешма ягыннан имзаланган Килешүне аннан алган көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә Килешү Акча белән баш эш итүче тарафыннан имзалана.

11. Килешүдә субсидиянең күләме, максатчан билгеләнеше, субсидия аларны финанслар белән тәэмин итү чыганагы булган чыгымнарның юнәлешләре, субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләре мәгънәләре, субсидияне күчерү тәртибе, субсидиядән файдалану хакында һәм субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турында хисаплылык тапшыру тәртибе, вакытлары һәм формалары, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияне субсидия алучы тарафыннан агымдагы финанс елында кайтару очраклары, Россия Федерациясе валюта законнары нигезендә югары технологияле импорт җиһазлары, чимал һәм комплектлау җайланмалары сатып алганда (кайтартканда) гамәлгә ашырыла торган операциялардән, шулай ук әлеге акчаны бирү максатларына

ирешүгә бәйле башка операцияләрдән тыш, алган акча исәбеннән чит ил валютасы алуны тыю турында нигезләмәләр, Акча белән баш эш итүче һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан коммерциячел булмаган оешманың субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен, коммерциячел булмаган оешманың әлеге Тәртип һәм Килешү шартларын үтәү турындагы нигезләмәне үтәвенә тикшерүләр гамәлгә ашыруга коммерциячел булмаган оешманың ризалыгы (дәүләт корпорацияләре һәм компанияләрдән тыш), коммерциячел булмаган оешманың кабул ителгән йөкләмәләрен үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплылыгы, шул исәптән коммерциячел булмаган оешма субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен бозган өчен штраф санкцияләре (кирәк булганда кулланыла торган) күздә тотыла.

12. Субсидия күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$C = P1 + P2 + P3 + ... + Pn,$$

монда:

С – субсидия күләме;

Р1, Р2, Р3 … Рn – әлеге Тәртипнең 4 нче пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән чараларны тормышка ашыруга юнәлдерелгән чыгымнар.

13. Акча белән баш эш итүче Килешүгә ике як та кул куйган көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә субсидияне коммерциячел булмаган оешманың Россия кредит оешмасында ачылган хисап счетына күчерә.

Коммерциячел булмаган оешма субсидияләр күчерү өчен каралган түләү реквизитлары үзгәрүе турында Акча белән баш эш итүчегә алдан ук, алар үзгәргән көннән соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итә.

14. Коммерциячел булмаган оешмалар субсидия акчасы килү һәм аны тоту буенча аерым бухгалтерлык исәбе алып барырга тиеш.

15. Коммерциячел булмаган оешма әлеге Тәртиптә һәм Килешүдә билгеләнгән шартларны бозган (Акча белән баш эш итүче һәм дәүләт финанс контроле органнары үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган) очракта, субсидия Татарстан Республикасы бюджеты кеременә Акча белән баш эш итүченең тиешле таләбен алган көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә кайтарылырга тиеш.

16. Килешүдә каралган очракларда хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр коммерциячел булмаган оешма тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты кеременә хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр кире кайтарылырга тиеш.

17. Субсидияне, әлеге Тәртипнең 16 нчы пунктында күрсәтелгән субсидиянең калган өлешен кайтару вакытларын бозган очракларда Акча белән баш эш итүче субсидияне, субсидиянең калган өлешен кайтару вакыты чыккан көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны мәҗбүри тәртиптә кайтару буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә чаралар күрә.

18. Акча белән баш эш итүче һәм дәүләт финанс контроле органнары әлеге Тәртиптә һәм Килешүдә билгеләнгән субсидияне кайтару шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүгә тикшерү үткәрә.

19. Субсидияләрдән максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны тикшерүдә тоту Акча белән баш эш итүче тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 5 июнь, 339 нчы
карары белән расланды

Татарстан Республикасы коммерциячел булмаган оешмаларының мәгълүмати порталын тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы коммерциячел булмаган оешмаларының мәгълүмати порталын тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр (алга таба – субсидия) бирү тәртибе механизмын билгели.

2. Субсидияләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм күрсәтү» ярдәмче программасының Татарстан Республикасы коммерциячел булмаган оешмаларының мәгълүмати порталын тәэмин итү буенча чараны үтәүче коммерциячел булмаган оешмаларга (алга таба – коммерциячел булмаган оешма) тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына (алга таба – Акча белән баш эш итүче) расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

3. Субсидияләр субсидия бирү турында килешү төзергә планлаштырыла торган айга кадәр килгән айның beресенә түбәндәге таләпләргә туры килгән коммерциячел булмаган оешмаларга бирелә:

коммерциячел булмаган оешма Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән һәм үзенең эшчәнлеген гамәлгә ашыра;

коммерциячел булмаган оешманың Россия Федерациясе законнары нигезендә үтәү вакыты җиткән Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычы булмаска тиеш;

коммерциячел булмаган оешманың Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләре (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән) кайтару буенча вакыты чыккан

бурычы һәм Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына башка вакыты чыккан бурычы булмаска тиеш;

коммерциячел булмаган оешма үзгәртеп оештыру, ябылу, банкротлык процессында тормаска тиеш һәм аның хуҗалык эшчәнлеген алып гамәлгә ашыруга чикләүләре булмаска тиеш;

коммерциячел булмаган оешма теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган салым салуның ташламалы салым режимы бирә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләре үткәргәндә мәгълүмат ачу һәм бирү күздә тотылмаган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналар) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган устав (җыелма) капиталларындагы чит ил юридик затлары катнашу өлеше барысы бергә 50 процентан арткан чит ил юридик заты, шулай ук Россия юридик заты булмаска тиеш;

коммерциячел булмаган оешма башка норматив хокукый актлар, муниципаль хокукый актлар нигезендә әлеге Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатларга Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан акча алучы булмаска тиеш.

4. Субсидия аларны финанслар белән тәэмин итү чыганагы булган коммерциячел булмаган оешма чыгымнары юнәлешләре булып түбәндәгеләр тора:

хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру;

хезмәт өчен түләүгә исәпләнгән акча;

интернет-портал булдыру өлкәсендә идарә системасы сатып алу;

интернет-порталга хезмәт күрсәтү белән бәйле башка чыгымнар.

5. Субсидия алу өчен коммерциячел булмаган оешма Акча белән баш эш итүчегә түбәндәге документларны тапшыра:

Акча белән баш эш итүче раслаган форма буенча субсидия бирүгә заявка;

субсидия аларны финанслар белән тәэмин итү чыганагы булган чыгымнарның юнәлешен раслый торган документлар (финанс-икътисадый нигезләмә);

кредит оешмаларында ачылган хисап (агымдагы) счетлар турында салым органы биргән яки раслаган белешмә;

коммерциячел булмаган оешманың штат расписаниесе;

узган финанс елы өчен коммерциячел булмаган оешма Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлеген җайга сала торган федераль законнарның аерым нигезләмәләрен тормышка ашыру чаралары турында» 2006 ел, 15 апрель, 212 нче карары нигезендә Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә тапшырган хисаплылык күчермәсе;

коммерциячел булмаган оешманың әлеге Тәртипнең 3 нче пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында коммерциячел булмаган оешма җитәкчесе һәм баш бухгалтеры имзалаган белешмә;

Россия Федерациясе законнары нигезендә үтәү вакыты җиткән Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычы булмавы, шулай ук Россия Федерациясе бюджет

системасы тиешле бюджетына башка бурычлары булмавын раслый торган документ;

коммерциячел булмаган оешманың үзгәртеп оештыру, ябылу, банкротлык процессында тормавы һәм аның хуҗалык эшчәнлеген алып гамәлгә ашыруга чикләүләре булмавы турында коммерциячел булмаган оешма җитәкчесе имзалаган гарантия хаты.

Документлар коммерциячел булмаган оешма тарафыннан кәгазьдә һәм электрон мәгълүмат саклау җайланмасында тапшырыла.

Тапшырыла торган мәгълүматларның дөрес булмавы өчен коммерциячел булмаган оешмалар Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап тота.

6. Акча белән баш эш итүче гаризаны кертелгән көнендә терки һәм документлар тапшырылган көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә аларны карап тикшерә һәм субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту хакында карар кабул итә.

7. Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

а) әлеге Тәртипнең 5 нче пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

б) тапшырылган документларның, аларда булган мәгълүматларның әлеге Тәртиптә каралган таләпләргә һәм шартларга туры килмәве;

в) коммерциячел булмаган оешма биргән мәгълүматның дөрес булмавы.

Документлар әлеге Тәртипнең таләпләренә туры килмәгән очракта Акча белән баш эш итүче алар кертелгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган ике көн эчендә коммерциячел булмаган оешмага бу турыда хәбәрнамә җибәрә.

8. Субсидия бирү өчен нигез булып Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән бертип форма нигезендә Акча белән баш эш итүче һәм коммерциячел булмаган оешма арасында төзелә торган субсидия бирү турында килешү (алга таба – Килешү) тора.

9. Субсидия бирү турында карар кабул иткән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә Килешү проекты Акча белән баш эш итүче тарафыннан коммерциячел булмаган оешмага имзалау өчен җибәрелә.

10. Коммерциячел булмаган оешма ягыннан имзаланган Килешүне аннан алган көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә Килешү Акча белән баш эш итүче тарафыннан имзалана.

11. Килешүдә субсидиянең күләме, максатчан билгеләнеше, субсидия аларны финанслар белән тәэмин итү чыганагы булган чыгымнарның юнәлешләре, субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләре мәгънәләре, субсидияне күчерү тәртибе, субсидиядән файдалану хакында һәм субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турында хисаплылык тапшыру тәртибе, вакытлары һәм формалары, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияне субсидия алучы тарафыннан агымдагы финанс елында кайтару очраклары, Россия Федерациясе валюта законнары нигезендә югары технологияле импорт җиһазлары, чимал һәм комплектлау җайланмалары сатып алганда (кайтартканда) гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән, шулай ук әлеге акчаны бирү максатларына ирешүгә бәйле башка операцияләрдән тыш, алган акча исәбеннән чит ил валютасы

алуны тыю турында нигезләмәләр, Акча белән баш эш итүче һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан коммерциячел булмаган оешманың субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен, коммерциячел булмаган оешманың әлеге Тәртип һәм Килешү шартларын үтәү турындагы нигезләмәне үтәвенә тикшерүләр гамәлгә ашыруга коммерциячел булмаган оешманың ризалыгы (дәүләт корпорацияләре һәм компанияләрдән тыш), коммерциячел булмаган оешманың кабул ителгән йөкләмәләрен үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплылыгы, шул исәптән коммерциячел булмаган оешма субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен бозган өчен штраф санкцияләре (кирәк булганда кулланыла торган) күздә тотыла.

12. Субсидия күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$C = P1 + P2 + P3 + ... + Pn,$$

монда:

С – субсидия күләме;

Р1, Р2, Р3 … Рn – әлеге Тәртипнең 4 нче пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән чараларны тормышка ашыруга юнәлдерелгән чыгымнар.

13. Акча белән баш эш итүче Килешүгә ике як та кул куйган көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә субсидияне коммерциячел булмаган оешманың Россия кредит оешмасында ачылган хисап счетына күчерә.

Коммерциячел булмаган оешма субсидияләр күчерү өчен каралган түләү реквизитлары үзгәрүе турында Акча белән баш эш итүчегә алдан ук, алар үзгәргән көннән соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итә.

14. Коммерциячел булмаган оешмалар субсидия акчасы килү һәм аны тоту буенча аерым бухгалтерлык исәбе алып барырга тиеш.

15. Коммерциячел булмаган оешма әлеге Тәртиптә һәм Килешүдә билгеләнгән шартларны бозган (Акча белән баш эш итүче һәм дәүләт финанс контроле органнары үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган) очракта, субсидия Татарстан Республикасы бюджеты керемен ә Акча белән баш эш итүченең тиешле таләбен алган көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә кайтарылырга тиеш.

16. Килешүдә каралган очракларда хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр коммерциячел булмаган оешма тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты керемен ә хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр кире кайтарылырга тиеш.

17. Субсидияне, әлеге Тәртипнең 16 нчы пунктында күрсәтелгән субсидиянең калган өлешен кайтару вакытларын бозган очракларда Акча белән баш эш итүче субсидияне, субсидиянең калган өлешен кайтару вакыты чыккан көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны мәҗбүри тәртиптә кайтару буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә чаралар күрә.

18. Бюджет акчасы белән баш эш итүче һәм дәүләт финанс контроле органнары әлеге Тәртиптә һәм Килешүдә билгеләнгән субсидияне кайтару шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүгә тикшерү үткәрә.

19. Субсидияләрдән максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны тикшерүдә тоту Акча белән баш эш итүче тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.